**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы №26 04 март 2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Микулино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү срокларын төгәлләштерү максатларында

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Микулино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә, 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«4.3. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча җирлек Советы яисә җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Микулино авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: И.А. Такиулин